## Фахриева Лена Рамазановна

Фахриева Л.Р. 1963 елда туган, югары белемле, 1987 елда Казан дәүләт медицина институтын, санитария табибы белгечлеге буенча санитария-гигиена факультетын тәмамлаган. Лена Рамазановна – һөнәри компетентлыкка ия җитәкче, инициативалы, тәҗрибәле, иҗади эшләүче, медицина училищесы коллективы эшчәнлеген Урта һөнәри белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларын тормышка ашыруга юнәлдерүче белгеч. Йогышлы авырулар укытучысының һәм укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасарының югары квалификация категориясенә ия. Мәгарифне яңартуның хәзерге заман тенденцияләре нигезендә үз хезмәтен һәм эшчәнлеген рациональ планлаштыра, укыту-тәрбия процессында катнашучылар белән төрле-төрле мөнәсәбәтләр кора белә. Аның җитәкчелегендә училищеда дәүләт белем бирү стандартлары нормалары һәм таләпләре нигезендә белем һәм тәрбия процессын оештыру өчен барлык шартлар да тудырылган. Барлык кабинетлар да заманча таләпләрне исәпкә алып җиһазландырылган. Ул коллектив эшенә компьютер технологияләрен актив кертә. Лена Рамазановна җитәкчелегендәге педагогик коллектив югары профессиональлек һәм квалификация дәрәҗәсе белән аерылып тора: югары һәм беренче квалификацияле педагоглар саны 41% тәшкил итә. Барлык укытучылар 100% югары белемгә ия. Училищеның барлык педагоглары да компьютерга ия, теоретик һәм практик дәресләрдә оста кулланалар.

Училище педагоглары аның җитәкчелегендә һөнәри осталык конкурсларында нәтиҗәле катнашалар. 2019-2022 елларда 25 укытучы Идел буе федераль округы урта һөнәри белем бирү укытучылары арасында үткәрелгән бәйгеләрдә призлы урыннар яуладылар. Лена Рамазановнаның турыдан-туры җитәкчелеге астында Яшел Үзән медицина училищесы базасында республика чаралары югары һөнәри дәрәҗәдә уза: Идел буе федераль округының медицина белем бирү оешмалары укытучылары арасында (2017 елның декабре), мәкаләләр җыентыгын нәшер итеп, читтән торып төбәкара фәнни-гамәли конференция әзерләнде һәм үткәрелде. 2018 елның апрелендә Яшел Үзән медицина училищесы базасында Татарстан Республикасы урта медицина белем бирү оешмалары студентлары арасында “Укыту-тикшеренү эшләре”нең республика конкурсы үткәрелде, аның нәтиҗәләре буенча, Фахриева Л.Р. республика конкурсын югары дәрәҗәдә оештырган һәм уздырган өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Рәхмәт хатын алды.

Компетентлы педагог һәм җитәкче Лена Рамазановна коллегалары белән эш тәҗрибәсе белән уртаклаша, педагогик һәм методик советларда, массакүләм мәгълүмат чараларында чыгыш ясый, тәрбия, хокук бозуларны кисәтү проблемаларын яктырта.

Республика, Россия һәм халыкара нәшриятләрдә үз эш тәҗрибәсен уртаклашу буенча күпсанлы публикацияләре бар. 2018 елдан башлап Яшел Үзән медицина училищесы чыгарылыш укучыларын беренчел аккредитацияләү әзерләү һәм үткәрү буенча зур оештыру эшен башкара.

Фахриева Л.Р. училище студентлары арасында тәрбия эшен оста оештыра. Ел саен студентлар муниципаль һәм республика конкурслары лауреатлары, төрле

дәрәҗәдәге спорт ярышлары призерлары булалар. 2011 елдан училищеның студентлар советы «Пульс» газетасын чыгара, анда училищеның студентлар тормышының актуаль проблемалары яктыртыла. Училище студентларының бик яхшы укуы һәм актив җәмәгать эшчәнлеге төрле дәрәҗәләрдә билгеләп үтелә: төрле елларда студентлар Зубринина А. һәм Шустова К. РФ Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан Республика оешмасы стипендиатлары булалар, 2017 елда «Шәфкать туташы эше» белгечлеге буенча III курс студенты Габдрахимова Г. Татарстан Республикасы Президенты стипендиясенә лаек булды.

Соңгы елларда төрле дәрәҗәдәге һөнәри конкурслар һәм олимпиадалар призерлары әзерләнде. 2014 елның май аенда Фәхриева Л.Р. Галәүтдинова Алия Казан шәһәренең «World skills Russia» эшче һөнәрләр буенча II Милли чемпионатында катнашты (сертификатка ия булды). Фәхриева Л.Р. World skills хәрәкәтен актив хуплый, 2018 елда Лена Рамазановна Казан шәһәрендә World Skills региональ этабында Яшел Үзән муниципаль районыннан «Медицина һәм социаль карау» компетенциясе буенча катнашучы юниорны Яшел Үзән медицина училищесы экспертлары тарафыннан әзерләүне җитәкләде һәм 2018 елда Яшел Үзән медицина училищесы студентлары Латыйпова Яна (төп состав) һәм Потапова Д. (юниор) көмеш призерлары булдылар. Алга таба ел саен 2019, 2020, 2021 елларда училище студентлары мактаулы призлы урыннар яуладылар.

2021 елда Яшел Үзән медицина училищесы «Дәвалау эшчәнлеге (фельдшер)» дигән яңа компетенция буенча World Skills ярышларын уздыру мәйданчыгы булды. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы (01.10.20021 ел, № 2137) нигезендә, оештыру комитеты төзелде, аңа укыту-тәрбия эшләре буенча директор урынбасары Фәхриева Л.Р. да керде: 5 мәйданчык булдырылды, экспертлар укытылды һәм республикада беренче тапкыр «Дәвалау эшчәнлеге (фельдшер)» компетенциясе буенча региональ этап уздырылды. Ярышларда Татарстан Республикасының 10 медицина көллияте (10 катнашучы һәм 10 тренер - компатриот) катнашты.

Училищеда волонтерлык ярдәме кысаларында берничә волонтерлык төркеме эшли, шул исәптән студентлар волонтерлар төркеме дә, ул шәһәрнең урта гомуми белем бирү мәктәпләре укучылары арасында сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау һәм начар гадәтләрне булдырмау буенча зур эш башкара. Лена Рамазановна Яшел Үзән районы үзәк хастаханәсе терапия бүлегенең элеккеге өлкән шәфкать туташы Игнатьева А.Г. җитәкчелегендәге сәламәтлек саклау ветераннары белән тыгыз элемтә булдыру инициаторы булды һәм волонтерлар Яшел Үзән Яшел Үзән районы үзәк хастаханәсенең сугыш һәм хезмәт ветераннарына шефлык ярдәме күрсәтәләр (фатирларны җыештыруда, азык-төлек һәм дару препаратлары сатып алуда булышалар). 2018 елның сентябрендә Яшел Үзән медицина училищесының студент-волонтерлары «ВОЛОНТЕР_МЕДИКЛАР» волонтерлык хәрәкәтенә кушылдылар һәм 2018 елның октябрендә ФАПның волонтерлык акциясендә һәм авыл халкына «АВЫЛГА - ИГЕЛЕК» ярдәмендә актив катнаштылар. Һәм, әлбәттә, COVID-19 яңа коронавирус инфекциясе пандемиясе чорында волонтер-медикларның ярдәме бәяләп бетергесез: студентлар туклану продуктлары, дару препаратларын өлкән яшьтәге ялгыз кешеләргә китерделәр һәм китерәләр, шәһәр һәм район

сырхауханәләрендә авыручылар һәм вакцинина алучылар турында мәгълүматларны теркәү эшен алып баралар, «Дәвалау эше» белгечлегендә укучы студентлар поликлиникаларда, өйгә чакыруларда һәм керү фильтрларында эшлиләр.

Фахриева Л.Р. тулы көч-куәт белән эшли, Россия мәгарифендәге һәм сәламәтлек саклау өлкәсендәге үзгәрешләргә җайлаша, педагогик һәм студентлар коллективы эшчәнлеген оештыруда культурологик алымнарга ия. Ул профессиональ компетентлык, максатчанлык һәм принципиальлек, башкарган эшенең соңгы нәтиҗәсе сыйфатлы булуына омтылучан булуы, коллегалар, студентлар һәм аларның ата-аналары белән үзара мөнәсәбәтләрнең катлаулы, күпкырлы дөньясын аңлый белүе белән аерылып тора.

Яшел Үзән медицина училищесында эшләгән елларда (34 ел 6 ай) Фахриева Л.Р., коллегалары белән бергә, Татарстан Республикасының күп кенә районнарында ихтыяҗ булган урта медицина звеносының меңләгән белгечен әзерләгән. Лена Рамазановна училище студентлары һәм коллегалары арасында гына түгел, Яшел Үзән муниципаль районы медицина хезмәткәрләре, Татарстан Республикасы медицина белем бирү уку йортлары җитәкчеләре арасында да хөрмәткә лаек.

Түбәндәге бүләкләре бар:

- Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының Мактау грамотасы, 2015 ел;
- Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Мактау грамотасы, 2004 ел.;
- Зеленодольск муниципаль районы администрациясе башлыгының Мактау грамотасы 2008 ел, 2014 ел,
- РФ Сәламәтлек саклау хезмәткәрләре профсоюзының Татарстан оешмасы президиумының Мактау грамотасы, 2008 ел.,
- «Татарстан Республикасының Мактаулы сәламәтлек саклау хезмәткәре» күкрәк билгесе, 2008 ел.